КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 август г.Казань № 703

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгын булдыру турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1260 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары Ослан, Зеленодольск, Лаеш муниципаль районнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгын булдыру турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1260 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 май, 410 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы турындагы нигезләмәдә:

4.2 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юынты суларны, шул исәптән дренаж суларны агызу;»;

әлеге карар белән расланган «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре урнашу урынының график тасвирламасында:

2 бүлектә:

утыз алтынчы юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «26 | 479651.562 | 1277509.384 | Картометрик | 5 | -»; |

егерме икенче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «112 | 478978.280 | 1268384.076 | Картометрик | 5 | -»; |


4 бүлектә:

чикләрнең күзәтү схемасын һәм битен үбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«4 бүлек**

## «Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре планы

Чикләрнең күзәтү схемасы




Масштаб 1: 300 000

Кулланыла торган шартлы билгеләр һәм билгеләмәләр:


- объектның чиге.

– муниципаль район, шәһәр округы чикләре.

## 4 бүлек

«Идел киңлекләре» төбәк әһәмиятендәге ландшафт юнәлешле дәүләт табигать тыюлыгы чикләре планы

1 бит




Ereräytü 1 : 65 000

Кулланыла торган шартлы билгеләр һәм билгеләмәләр:

- **• 1** - чикнең характерлы ноктасы.
- ——— - объектның чиге.
- – · – · – – муниципаль район, шәһәр округы чикләре.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин